**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

2021 ел, 07 ноябрь. № 3

Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең Кече Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Кече Сөнчәле авылы, Гагарин урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан, клуб бинасында билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Кече Сөнчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме?:

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Кече Сөнчәле авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Кече Сөнчәле авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш китерү, грунт һәм вак таш салу һәм тигезләү).

**Торак пунктлар чикләрендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- урам утларын агымдагы ремонтлау, урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алу;
- торак пункт эчендәге территорияне чүп үләненнән чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;**

- чүп контейнерлары алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы И.В.Крайнова

СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ